**Нурмөхәммәтова Р.С.,**
**гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасы**

# ТАТАР ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ “БОТКА” ЛЕКСЕМАСЫ

(мәкалә 11-14-16029а/В номерлы РГНФ гранты кысаларында эшләнде)

Татарлар – тарих дәвамында табигый һәм иҗтимагый-икътисади шартларга бәйле шактый үзгәрешләр кичергән халык. Әлбәттә, болар татар халкының милли ризыклары язмышына да тәэсир итми калмаган: күп кенә ризыкларны әзерләү тәҗрибәсе буыннан-буынга күчми калган, кайберләре матди яктан яңа эчтәлек алган, чит халыклардан кергән ризыклар үзләштерелгән. Әмма шундый шартларда да татар халкының элек-электән килгән матди һәм рухи байлыгын үзләрендә саклап калган ризыклар күпсанлы. Шундыйларның берсе – *ботка*. Ул борынгы һәм гади ризыклардан санала. Әгәр татарларның элек-электән игенчелек белән шөгыльләнүен исәпкә алсак, бу табигый да, чөнки ТТАСта бирелгәнчә, “ботка – ярмадан суда яки сөттә пешерелгән куе ашамлык” (ТТАС 2005, 94).

Бу ризыкның үзе кебек үк, атамасы да борынгы: гомумтөрки *ботка, бутка* сүзе “бутка, ярма”ны аңлата; монголча *будаа(н)*, борынгы монгол телендә *будаган* “ярма, бутка, кыздырылган ярма, талкан” сүзеннән. Чыгышы бик ачык түгел, *бута-у* белән аңлату акланып бетми.

Бик борынгы заманнардан игенчелек белән шөгыльләнгән татарларның көндәлек тормышында төрле ярмалардан пешерелгән боткалар зур урын алып торган. Бигрәк тә тары ярмасы киң кулланылган, чөнки ул Идел буе болгарлары арасында киң таралган була. Бодай боткасы көндәлек ризык кына булып калмаган, бәйрәмнәрдә дә яратып әзерләнгән, хәтта йола ашамлыгы буларак та йөргән. Болардан тыш борай, борчак, карабодай ярмалары да файдаланылган. Дөгене сатып алганнар, шуңа күрә ул бәйрәм ашлары әзерләүдә генә кулланылган.

Төрле ярмалардан пешерелгән боткалар бала туу, йорт салу, җир эшләре һәм терлекчелек белән бәйле йолаларның аерылгысыз атрибуты булган.

Телдә еш кулланыла торган сүзләрнең еш кына өстәмә мәгънәләре барлыкка килә, *ботка* сүзе белән дә шулай була: ул “тәртипсез буталчыклык; артык күп, кирәксез күп булган нәрсәләр” төшенчәләрен дә белдерә башлый.

Халыкның көндәлек тормышында әһәмиятле урын тоткан әлеге ризык атамасы аның тормыш тәҗрибәсен, зирәк акылын чагылдырган мәкальләргә дә кереп киткән. Н.Исәнбәтнең өч томлык “Татар халык мәкальләре” хезмәтендә ботка сүзе кергән 80 нән артык мәкаль теркәлгән. Менә аларның кайберләре: авызы пешкән туң *ботка*ны өреп кабар; аз *ботка*га күп сүз; артык кашык майдан *ботка* бозылмый; бер казанда аш белән *ботка* бергә пешми; бер

тарыдан *ботка* булмас, б*отка* булса, йортка булмас; *борай боткасы* каз өмәсендә тәмле; *ботка* ашаганның буыны нык, өйрә ашаганның буыны сыек; *ботка* пешергәч, ярманы кызганмыйлар; *ботка* пешкәнме-юкмылыгын бер тарыдан да белеп була; булган кеше *botka*ны үз ягына җыра; кайгың *карабодай боткасы* булсын; кешенең *ботка*сыннан үз өйрәң әйбәтрәк; коры судан *ботка* пешми; күпкә киткәч, майлы *ботка* да туйдыра; куе булса, *ботка* булыр, сыек булса, өйрә булыр; өйдә эткә апара болгата белмәгән, илдә *ботка* болгаткан; өйрә астан суына, *ботка* өстән суына; эш майлы *ботка* түгел; ярар безгә – майлы күзгә әйрән каткан *ботка* да; ярый безгә тансыкка *тары боткасы* һ.б.

Фразеологизмнарда да *ботка* сүзе еш очрый, ул анда туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла: *авыз эчендә ботка пешерү; авызында ботка кайнату; авызда ботка пешерү* – авызы боткага пешкән кебек, сүзне-җөмләне рәтләп әйтә алмыйча, телендә чатыл-потыл әйләндерә-әйләндерә әвәләп, аңлаешсыз, бутап сөйләшүче турында; *ата каз боткасы* – махорка, яфрак тәмәке; *ботка күзе* – ботканың уртасында кашык белән ясалган май чокыры; *ботка пешереп алган урын* – берәү һәрвакыт бер җиргә, бер урынга утырса, шулай диләр; *ботка пешерү* – бергәләп берәр эш куерту, эш майтару; *ботка пешү* – уртак тел табып яки үзара килешеп, дус-тату эшләү; *боткага авыз пешү* – берьюлы мал-дәүләткә, дәрәҗәгә ирештем дигәндә, ашыгуы белән эшне бозу, насыйп булмый калу; *боткадан боламыкка калган* – башлаган эше барып чыкмаган, эше начарайган; *ботканы пешердең, үзең аша* – бик белдеклеләнеп, бер ярамаган эш куертып, нәтиҗәсе начар булып чыккач, бәлане берәр дус-ише йә якынына күтәртмәкче булганда әйтелә; *ботканың күзен үз ягыңа аеру* – эшне үз файдаңа бору, үз ягыңа каеру (элек бер табактан бергәләп ботка ашаганда, ботка күзен кашык белән ерып, майны үз ягыңа каерып агызудан калган); *боткасы ботка, мае май килеш* – ничек булган шул килеш, оешмаган; *боткасы бүртмәү* – куерткан эше барып чыкмау; *булган-булган, ботка булсын* – берәр эшне артык куерта, бутый торгач, бөтенләй башка бер эш китереп чыгарудан көлеп әйтелә; *карга боткасы* – яз ахырларында, сабан туе һәм яңгыр теләү көннәрендә балаларның халыктан май, ярма җыеп, елга буенда казан асып, уен-бәйрәм корулары; *кәгазь боткасы* – һәртөрле рәсми кәгазьләр, анкеталар, кәнсәләрчелек волокитасы; *ни тары, ни ботка; ни ярма, ни ботка* – бер эшкә дә ярамаган, икенең берсе дә була алмаган, пешмәгән, уңмаган кешегә мисалдан әйтелә һ.б.

Бу лексеманың җырларда очравы шулай ук гаҗәп түгел. “Тәти кашык базарда, Майлы *ботка* казанда, Әти китте базарга, Кызыл үгез бар анда. Әти кайткач базардан, *Ботка* төшәр казаннан, Кояш, чык, чык, чык!” такмагын кем генә хәтерләми икән.

Табында бәрәңге күргән саен, “Вак-вак итеп турап, яшь киленнәр Табаларда сине биетә; Булы *ботка*ң ашап, эшчән ирләр Тәннәренә җылы йөгертә” (“Бәрәңге”, И.Хисамов көе, М.Хөсәен сүзләре) дигән җыр сүзләре искә төшә.

XX-XXI гасырларда иҗат иткән һәм иҗат итүче һәр татар язучысының әсәрендә дә әлеге лексеманы очратырга була. Кадыйр *ботка*ны кашыгы белән әйләндерә-әйләндерә алып бер-ике капты да табакны читкәрәк этеп куйды (Н.Дәүли “Язмышка юл”). *Борчак буткасы* ашыйсыңмы, вак бәлеш биримме, кайнар ит бөккәнеме, әллә бавырсак белән чәйләп җибәрәсеңме? <…> Табын уртасына җыйнак кына табак белән кайнар *борай боткасы* куелган, аңа чокырлап сары май салынган иде (Г.Бәширов “Гыйбрәт”). Мин сиңа бер эш таптым, үзе ашлы, үзе тузансыз, кичен яныма кил, туйганчы *ботка* ашарсың (И.Сәләхов “Фаҗига”). Соңыннан билгеле булганча, тәҗрибәсез кыз бер айлык балага *бодай боткасы* пешереп ашаткан булган икән (Ә.Баянов “Урланган ай”). Сөткә пешкән, бераз май белән тәмләтелгән саргылт *ботка*ның хуш исе әле дә борынны кытыклый шикелле (К.Тимбикова “Тын бакчада”). Билләһи, барысын да җыеп, Тукай әкиятендәгечә, *итле ботка* гына ашатып асрар идең! (М.Мәһдиев “Кеше китә – җыры кала”). Кемдер аңа калай савытта *ботка* алып килде (А.Хәлим “Өч аяклы ат”). Сөт-май булганда шул черек бәрәңге оныннан пешерелгән *ботка*ның нинди тәмле булуын әйткән дә юк инде (В.Нуруллин “Шинельсез солдатлар”). Шуны Мәгузә килен кул тегермәненнән үткәреп ярма иткән дә, *ботка*сын пешергән (З.Зәйнуллин “Сугыш алды малайлары”). Бу артыксыну малайның ике кашык *борчак боткасы* ашавыннан түгел, кырдагы игенчеләргә дип пешергән ризык һәрвакыт артып кала... (К.Кәримов “Сакау күке”). Үз теләге белән тозлы *тормыш ботка*сы пешергән Казанына кайтарып җибәрергәме? (Җ.Дәрзаман “Җир авазы”). Казанда пешкән *сөтле ботка*дан бер бөртек тары сикереп чыга алмый, Гөлфия Хан (Н.Гыйматдинова “Сер”). *Солдат боткасы* капмас борын кем аны шундый җиңел урынга урнаштыргандыр, үзен нәкъ “гражданка”дагыча иркен тота (З.Хөснияр “Каешлану”). Фирая карамый гына *ботка* салынган тәлинкәне куйды да (әзмени монда кереп-чыгып йөрүче егетләр) компот салып стакан сузды (Д.Буләков “Ачык ишек”) һ.б.

Шулай итеп, татар лингвомәдәнияте үрнәкләрендә “ботка” лексемасының гаять күп кулланылуы исбатланды. Ул халыкның тормыш тәҗрибәсен, яшәү шартларын, фикерләү үзенчәлекләрен ачыклауда бик мөһим роль уйный, башкача әйткәндә, милли мәдәниятнең үзәгенә үтәргә ярдәм итә. Башка барлык халыкларда да актуаль булган әлеге ризык һәм аның атамасы хәзерге традицион туклану культурасы үткәнгә калып барган чорда да әһәмиятен югалтмас. Димәк

әле бу берәмлек кергән халык иҗаты үрнәкләре, телдән-телгә күчеп, киләчәк буыннарга да барып җитәр дип ышанасы килә.

**Әдәбият**

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г.Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы / Ф.С.Баязитова. – Казан: Дом печати, 2007. – 480 б.

Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении / Р.Р.Замалетдинов. – М.: Гуманит. издат. центр ВЛАДОС; Казань: Магариф, 2004. – 239 с.

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 т. (А-К), 2 т. (Л-Һ) / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – 2-нче басма / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Хайрутдинова Т.Х. Названия пищи в татарском языке / Т.Х.Хайрутдинова. – Казань, 1993. – 142 с.